**"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге «муниципаль берәмлегенең**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«20» ноябрь 2019 ел № 2

**Гажданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге составына керүче Түбән Оча авылында Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы нигезендә», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст.», Мамадыш муниципаль районы Түбән Оча авылында 2019 елның 20 нояберендә узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

" Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Оча авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннар, көндезге бүлектә белем алучы студентлар кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Түбән Оча авылы торак пункты урамнарын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Түбән Оча авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Түбән Уча авылы зираты территориясендә хуҗалык төзелеше (материаллар сатып алу, төзелеш, килешү буенча эш өчен түләү)

« ӘЙЕ» «ЮК»

соравы буенча 2019 нчы елның 20 нче ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 152 граждан кертелгән;
гражданнар җыенында катнашучы 101 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе " позициясе өчен»- барлыгы 101 кеше тавыш бирде;
“Юк” дип тавыш бирүче булмады.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Түбән Оча авылында үткән гражданнар җыенын- уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип таныйрга.

2. Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Оча авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип таныйрга:

" Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Оча авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннар, көндезге бүлектә белем алучы студентлар кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Түбән Оча авылы торак пункты урамнарын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Түбән Оча авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
-Түбән Уча авылы зираты территориясендә хуҗалык төзелеше (материаллар сатып алу, төзелеш, килешү буенча эш өчен түләү)

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Җ.Хәмизуллин